**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 24 октябре 385№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 7 декабрендәге «2022 елда Әлки муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның һәм инвалид балаларның кайнар туклануын оештыру турында» 518 номерлы карарына өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 647 номерлы Әмере, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 7 декабрендәге «2022 елда Әлки муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның һәм инвалид балаларның кайнар туклануын оештыру турында» 518 номерлы карарына өстәмәләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 7 декабрендәге «2022 елда Әлки муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның һәм инвалид балаларның кайнар туклануын оештыру турында»518 номерлы карарына түбәндәге эчтәлекле 6.3 пункт өстәргә:

«6.3. Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балалары».

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ:

3.1. 2 пунктта күрсәтелгән ташламаны хәрби комиссариатның өлешчә мобилизация кысаларында укучы ата-анасын (законлы вәкилен) хәрби хезмәткә чакыруы турындагы белешмәсе нигезендә бирергә;

3.2. өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта ташламаларның гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максаты белән хәрби комиссариат белән хезмәттәшлекне алдан карарга.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар балаларын түләүсез кайнар туклануны оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы гражданның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт узу вакытына 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ начальнигына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.Х.Морадымов

Сәлахова Р.М.
21700